ЯШЕЛ БИШЕК

ТР ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГЫЙ БАЙЛЫКЛАР МИНИСТРЛЫГЫ БЕЛӘН ӘЗЕРЛӘНГӘН МАХСУС КУШЫМТА

Автомобильләр тикшерелә

15 майдан алып 23 июльгә кадәр республикада "Чиста һава" операциясе узды.

Аны экология һәм табигый байлыклар министрлыгының Экологик иминлекне тәэмин итү дәүләт инспекциясе оештырды. Башкалада бу чара өчен ЮХИДИнең "Лаеш" һәм "Кояш баешы" ("Закат") постлары җаваплы иде. Барлыгы 1773 машина энә күзеннән үткәрелде. Шулардан 544енең һавага пычрак матдәне нормадагыдан күбрәк бүлеп чыгаруы ачыкланган. Операция барышында 41 хокук бозу очрагы теркәлеп, җиде мең сумга якын штраф салынган.

"Чиста һава" операциясе вакытында Кама буе регионындагы 13 автотранспорт предприятиесендә тикшерү үткәрелде. Экологлар кармагына эләккән 152 берәмлек автотранспортның 21 е пычрак һәм зararлы газларны нормадан зуррак күләмдә чыгара икән. ЮХИДИнең "ТУЛА №1" постында 306 берәмлек транспорт чарасыннан анализ алынган. Алардан 106 сының һаваны пычрату чыганагы икәнлеге беленгән. Монда төп сәбәп транспорт чараларыннан дөрес файдаланмау, ягу аппаратларының төзек булмавы һәм ягулык-майлау материалларының сыйфатсыз булуында. Экологик тәртип бозучылар административ җаваплылыкка тартылган.

Эт өрә, бүре йөри

Узган атнада экология милициясе хезмәткәрләре тарафыннан 7 җинаять эше кузгатылган. Аларның өчесе законсыз рәвештә агач кисү белән бәйле. Мондый башбаштаклык Чишмә һәм Татарстан урманчылыгында ачыкланган. Шулай ук Түбән Кама районының Кама Аланы бистәсеннән ерак булмаган юл буенда да бер җинаятьче 20 өрәңге агачына зыян китергән. Ул моның өчен тиздән җавап тотачак.

Зөя елгасында тотылган балык браконьерларын шулай ук суд көтә. Экология милициясе инспекторлары аларның электр кармакларын тартып алган.

Узган атнада Татарстанда барлыгы 601 административ хокук бозу очрагы ачыкланган. Аларның биш йөзгә якыны муниципаль район һәм шәһәр округларындагы тормыш шартларын яхшыртуда җибәрелгән кимчелекләргә бәйле. Иң күп хокук бозу очраклары Казан һәм Казан яны, Чаллы, Әлмәт, Түбән Кама һәм Алабуга кебек зур шәһәрләр территорияләрендә ачыкланган.

Ун очрак җир кишәрлекләреннән рөхсәтсез файдаланыга бәйле. Су объектларын саклау буенча билгеләнгән кагыйдәләргә бармак аша караучылар да җитәрлек икән. Шундый утыздан артык очрак экологларны уйланырга һәм чара күрергә мәҗбүр иткән.

Шунысы гаҗәп: табигать саклаучылар кырысрак эш иткән саен, тәртип бозучылар үрчи бара. Кем әйтмешли, эт өрә, бүре йөри тора.

ХАТ

Аптырыйм

Хәзер баласыз гаиләләр ифрат күбәеп китте. Моны экологиянең начарлануы белән дә аңлаталар, башка сәбәпләр дә табалар. Бервакыт автобуста кайтып барганда, яныма эт күтәргән бер чибәр генә ханым килеп утырды. Утыруы булды, сумкасыннан әллә ниткән чүпрәкле әйберләр чыгарып, этен киендерергә дә тотынды. Баксаң, эт пальтосы икән чүпрәк дигәнем. И-и, сөйләшә эт белән. "Салкын тияр, һава юеш", – дигән була. Баласын юатамыни?! Бу күренешкә автобустагыларның да исе китте булса кирәк. Барысының да аптыраулы карашлары әлегә ханымга юнәлде. И Ходаем, бала тудыру сәләте була торып, бала урынына шул рәвешле эт тәрбияләп ятучылар аз түгел шул хәзер.

Рафаэль САЛЬМУШЕВ

Каравыл, чүп җитми

Берәүләр чүпне кая куярга дип баш ватканда, икенчеләр аны каян алырга белми тилмерә

Татарстан Республикасының экологик куркынычсызлык, табигатьтән файдалану һәм санитар-эпидемиология иминлеге буенча ведомствоара комиссия утырышының берсе Актаныш районында Татарстан Дәүләт Советының экология, табигатьтән файдалану һәм аграр мәсьәләләр комитеты белән берлектә үтте. Көн тәртибенә каты көнкүреш калдыкларын җыю, аралау, икенчел чималны эшкәртүнең тулы бер челтәрен булдыру мәсьәләсе куелды.



Киләсе елга 300 еллыгын тутырачак Актаныш чәчәкләрә күмелеп утыра. Шуның өстенә биредә һәр тарафның чиста, пөхтә булуына, яшеллекнең күплегенә игътибар итәсең. Бу районда табигатькә сак караш урнашуын сизми мөмкин түгел. Шулай да аларда каты көнкүреш калдыкларын җыю һәм эшкәртү өлкәсендә проблемалар булган икән. Бу юлы чүп түгә торган мәйдан һәм аның янындагы махсус ангарда урнашкан чүп аралау линиясен карагач, экология һәм табигый байлыклар министры Әгъләм Садретдинов: "Биредә уңай якка үзгәреш шактый булган", – дигән нәтиҗә ясады.

Комиссия әгъзалары һәм депутатлар Актанышның агрегат заводын, җиһазландыру дәрәҗәсе һәм мәйданы буенча шәһәрнекеннән һич калышмаган "Лачын" боз сараен да карап чыктылар. Яңа гына ремонтланган тораклар белән танышып үттеләр. Һәркайда хужа кулын күрергә, булсынга эшләүне тоемларга була. Өйләрнең тирә-ягы чәчәккә күмелгән, эскәмияләр буялган, уен мәйданчыкларында балалар мәш килә.

Экологик иминлеккә ирешү өчен федераль, җирле үзидарә органнарының, Актаныштагы кебек, килешеп эшләве зарур. Министр чыгышындагы иң әһәмиятле фикер әнә шул булды. Федераль законнар нигезендә калдыкларны җыю, утильләштерү, эшкәртү вазыйфасы муниципаль берәмлекләргә йөкләнгәч, җирле үзидарә органнарының экологик куркынычсызлыкны тәэмин итүдә роле үсте. Әмма бу кем ничек тели, шулай эшли дигән сүз түгел. Дәүләт хакимияте органнары аларга программалар төзү, шуларны үтәтү, каты калдыклар белән эшләү челтәрен булдыру, махсус техника алуда ярдәм итү өчен җаваплы. Беркемгә дә сер түгел: әлегә республикада каты калдыкларны тәртип белән җыю хәл ителеп бетмәгән. Мәсәлән, эре сәнәгать үзәге булган Яшел Үзәндә бүген дә каты көнкүреш калдыклары полигоны юк икән. Якын арада анда һәм Казанда, Алабугада, Баулыда, Чистайда, Биектауда, Лаешта һәм Балык Бистәсендә – барлыгы 8 төбәктә чүп мәйданы төзү планлаштырыла.

Безнең илдә һәркем көненә кимендә 2-3 килограмм чүп "ясый". Менә шуның кадәр калдыкны ничек юк итәргә була соң? Министрның беренче урынбасары Марат Мәһдиев Россиядә, шул исәптән Татарстанда бик кискен торган әлегә сорауга җавап бирергә тырышты. Аныңча, чүпне юк итүнең өч юлы бар. Моның бездә иң таралганы – араланмаган чүпне махсус мәйданга чыгарып күмү. Бу авыл хужалыгы җирләренең кимүенә китерә. Икенчел чимал булырлык калдыклар мәңгелеккә җир астында кала. Чүп-чардан котылуның икенче юлы – яндыру. Анысы, зararлы газлар чыгарып, табигатькә зур зыян сала. Әлбәттә, иң отышлы ысул – чүпне чималга әйләндерү. Ләкин полиэтилен элпә, пластмасса, сөт һәм җиләк-җимеш суларыннан бушаган ПЭТ-каплар, кәгазь, пыяла һәм башкаларны икенчел чимал исәбенә кертә башлавыбызга күптән түгел шул әле. Урынбасар, галимнәр фикеренә таянып, сәнәгать калдыкларының 50-80 процентын, каты көнкүреш калдыкларының 25 процентын югары технологияләр ярдәмендә эшкәртергә мөмкин дип раслый.

Әлегә эшнең беренче баскычы – калдыкларны аралау. Татарстанда хәзерге көнгә шундый 15 комплекс бар. Алар ярдәме белән калдыкларны эшкәртмичә чүп базларына ташлау былтыр 4 мең тоннага кимегән. Республикада җыела торган көнкүреш һәм сәнәгать калдыкларының 16 проценты, ягъни 802 тонна чүп кабат эшкәртелеп, аннан чимал алынган. Ул комплексның һәркайсы ун төрле икенче чимал "җитештерә". Калдыкларны урында эшкәртүчеләр дә бар. Минзәләдәгәсе, мәсәлән, араланган полимерны урам плитәсе – брусчатка калыплау өчен файдалана. Баулы полигоны да тротуар плитәсе, черепица эшләп чыгара. Азнакайда торак-коммуналь хуҗалык өчен кирәкле әйберләр, мәсәлән, себерке ясала.

Татарстанда төзелеш материалларын эшкәртү өчен ваклау ысулыннан файдаланалар. Моңа кадәр төзелештән калган тимер-бетон материалны кая куярга белмичә аптырыйлар иде. Хәзер Казанның Салмачы бистәсендә "Сервис-универсал" ширкәте аларны кабул итә.

Соңгы еллардагы тырышлык нәтиҗәсендә республикада чүп җыю һәм аралаучы махсус оешмаларның тулы бер челтәре барлыкка килде. Ул лицензиягә ия булган 178 оешмадан (юридик һәм физик затлар) тора. Шуларның 75 е – кара һәм төсле металл эшкәртүгә, 69 ы – икенчел чимал эшкәртүгә, 23 е чүп полигоннарыннан файдалануга хокуклы.

Бердәм эшләүнең нәтиҗәсен инде бүген үк күрергә мөмкин. 2006 елда 496 мең тонна чүпне җыеп эшкәрткән булсалар, былтыр ул сан ике тапкыр диярлек зуррак булган. Иң мөһиме: шуның биштән ике өлеше эшкәртелгән. Әлегә челтәрнең уңышлырак эшләвенә комачаулаучы сәбәп бар: ул да булса – җыю пунктлары оештырылмау. Мондый эшчәнлек белән хәзергә Чаллы һәм Казан гына шөгыльләнә.

Шунысы гаҗәп: кайберәүләр чүпне кая куярга белми тилмергәндә, икенчеләр аны каян алырга дип баш вата. Мәсәлән, Салмачыдагы корылманың куәте – сәгатенә 150 тонна. Әмма аңа эшкәртү өчен чимал җитешми. Кайберәүләр сәнәгать калдыкларын өеп тоту, йә булмаса Самосыр чүплегенә ыргытуны өстен күрә. Яшел Үзән районындагы "Экопәк" ширкәтендә дә шуңа охшаш хәл. Бирегә Италиядән кайтартылган корылма айга 1000 тонна ПЭТ-калдыклар – сөт һәм җиләк-җимеш сыекчаларыннан бушаган капларны эшкәртергә сәләтле. Әмма аңа һич кенә дә кирәк кадәр күләмдәге чүп килеп ирешми.

Ләйсән ФӘҺИМОВА

КЫЗУ БУЛАЧАК

Су һәм һава өчен штраф

Табигатьнең җылынуы хакында хәзер Ак йортта ук сүз алып бара башладылар. Елдан-ел температураның күтәрелүенә сәнәгать предприятиеләренең күп булуы һәм аларның галәмгә зур күләмнәрдә газлар чыгаруы тәэсир итә. РФ Табигый байлыклар министрлыгы моңа каршы көрәшне көчәйтү өчен эре предприятиеләрнең эшчәнлеген кискен күзәтү астына алырга кирәк дип саный. Суны, һаваны, җирне пычратучылар бик зур күләмдә салым түләргә тиеш булачак. Әйтик, сулыкларга сәнәгать калдыкларын ташлаган өчен түләү 2011 елдан ике тапкырга, ә 2016 елдан 9 тапкырга артачак.

1,5 градуска җылыну

Табигый байлыклар министры Юрий Трутнев, махсус программалар төзегәндә алдагы йөз елда булачак температураны күздә тотып эш итәргә кирәк, дип исәпли. Мәсәлән, һава җылыну Хөкүмәтнең кышкы чордагы чыгымнарын киметәчәк. Нефть һәм газ чыгаручы компанияләргә арктик салкынлык төбәкләрендә эшләү җиңеләячәк. Авыл хуҗалыгында моңа кадәр өлгерми торган культураларны үстерү мөмкинлеге туачак. Тискәре йогынты да сизеләчәк. Бигрәк тә мәнге туңлык төбәкләрендәге нефть һәм газүткәргечләренең торышы начараячак.

Климат мәсьәләсендә 2050 елга кадәр өч төрле фараз әзерләнгән. Беренчесе – пессимистик. Ул икътисад үскән саен әйләнә-тирә мохитнең ныграк пычрануын күздә тота. Икенчесе – уртача хәвефле фараз. Анысы сәнәгатьне яңарту бәрабәренә экологиядә иминлекне саклау мөмкин, дип исәп итә. Өченчесе – оптимистик гоманлау. Моңысы сәнәгать предприятиеләрен үзгәртеп кору нәтиҗәсендә һавага зararлы газлар чыгаруны кисәк киметүне күздә тота. Өч сценарий буенча да 2020 елга Россиядә һава температурасының 1,5 процентка күтәрелүе көтелә. 2050 елга ул хәтта 2,7 градуска югарырак булырга мөмкин.

"Майлы" арифметика

Табигый байлыклар министрлыгында 1 куб метр нәҗәс суны чистарту дәүләткә күпмегә төшкәнен исәпләп чыгардылар. Менә шуны предприятиеләрдән чыга торган пычрак сулар күләменә тапкырлагач, 360 миллиард сум килеп чыга. Ул кадәр сыеклыкны чистарту өчен җитәрлек корылмалар төзүгә ун елдан артык вакыт китәчәк. Димәк, казнага ел саен 36 миллиард сум акча керергә тиеш. Бүгенге көндә "пычрак сулар" өчен предприятиеләрдән бюджетка күчерелә торган акча нибары 4 миллиард сум тәшкил итә.

Японнар кызыксына

Күптән түгел Татарстан Экология һәм табигый байлыклар министрлыгында Япония делегациясе булып китте. Аларны Менделеевск шәһәрендә төзеләчәк азот ашламалары заводының экологик куркынычсызлыгы кызыксындыра. Японнар бу максатка үз проектларын тәкъдим итәргә телиләр.

Без башкалардан кимме әллә?

Дүрт районда ачык сулыкларга ел саен 11 млн 200 мең кубометрдан күбрәк калдык су төшә. Аның күп өлеше чистарту узмый

Экология һәм табигый байлыклар министрлыгының Менделлевскида узган күчмә утырышы да, гадәттәгечә, мондагы хәлләр белән танышудан башланып китте.

Кала урамнары буйлап үтеп, каты көнкүреш калдыклары полигонында булгач һәм "Карпов исемендәге химия заводы"ААҖнең икенчел продуктларны эшкәртү цехы белән танышкач, "Татгазэнерго" җәмгыятенә караучы биологик чистарту корылмалары биләмәсендә тукталды республика экологлары.

Мөгаен, министр Әгъләм Садретдиновның киңәшмәне үзе үткәрәсен белептер, бирегә Самара каласындагы "Самэнвиро" Россия–Голландия уртак предприятиесе вәкилләре дә килеп җиткән. Блгеле инде, максатлары – үз продукцияләрен тәкъдим итү. Күршеләребезнең Голландия ярдәме белән калдык суларны чистарту өчен мембраналы технологияләр куллана башлауларына министр югары бәя бирде һәм бу ысулның алга киткән илләрдә, аерым алганда, күптән түгел үзе булып кайткан Сингапурда хәтсездән кулланышка кертелгән булуын искәртте. Ә.Садретдиновның әлегә фирма эшчәнлеген өйрәнергә кирәклегенә басым ясавы, "Самэнвиро" вәкилләренең күңелләренә сары май булып ятуы шикләндерми.

Нәкъ шул мизгелдә биологик чистарту корылмаларының участок мастеры Людмила Минеева, инициативаны кулына алып, экологларны үз биләмәләренә алып кереп китте. Бәй, биредә дә яхшы тормышның күктән төшкәнен көтеп, кул кушырып утырмаганнар икән ләбаса – былтыр, шактый саллы бәягә төшереп, Италиядән тәүлегенә 11 мең кубометр калдык суларны чистарта алучы ике дозатор (берсе – резервта) сатып алганнар. Инде кала халкы һәм сәнәгать предприятиеләре файдаланган сулар биредә чистару узып, Пойма елгасына агызыла. "Суның сыйфаты әйбәт, елгага безнең су төшкән урыннарда күпләп балыклар үрчи хәзер", – дип нәтиҗә ясады Людмила Валентиновна.

Ахырдан барып белешкән идем, бер проблемалары да бар икән үзләренең: элек тәүлегенә 10 ар мең кубометр су чистарта торган булсалар, инде аның күләме 5-6 меңгә калган. Сәбәбе – халыкның һәм предприятие житәкчеләренең сакчыл яши башлауларында. Ягъни мәсәлән, күпләр исәпләү приборлары куеп, суны чама белән генә сарыф итүгә күчкән. Шуннан бирле чистарту корылмаларының проект куәтләрен 60% ка гына файдаланырга мәҗбүрләр. Бу үз чиратында җитештерүчәнлеккә суга. Гәрчә моны проблема дип атавы да кыенрак. Андый проблемалар шулай ук киңәшмәгә чакырылы Әгерҗе, Алабуга, Мамадыш районнары вәкилләренә дә тәтесен иде дә бит. Юк шул! Алар табигатькә зыян китермәүләре белән әллә ни мактана алмыйлар әлегә.

Мамадыш халкы һәм предприятиеләр файдаланган сулар, канализация буйлап, май-сыр заводының чистарту корылмаларына килә. Шуннан нәрсә, дип котылыр идең дә, төбәк халкын күптәннән бимазалап торган проблема җиңнән тарта: май-сыр заводының чистарту корылмалары тәүлегенә 700 кубометр калдык суларны сафландыруга исәп тотып төзелгән, ә чынбарлыкта аның күләме ике мәртәбәдән дә артып китә. Шулай булгач, кайбер мәлләрне шакшы суларның ташып чыгып табигатькә каза салуына ничек аптырыйсың ди. Ә менә Әгерҗе районының Красный Бор авылында су чистарту корылмалары бөтенләй юк, калдык сулар турыдан-туры Түбән Кама сусаклагычына ага. Югыйсә авыл шактый ук зур, заманында 30 ел район үзәге булып торган. Бу көндә анда 1800ләп кеше яши.

Мактап телгә алсак та, шул ук Менделеев районында да Пойма һәм Кама елгаларына гел генә чистартылган калдык сулар агып ятмый. Мисал өчен, биредә яшәүчеләр тарафыннан районда ел саен 3,23 млн кубометр калдык сулар хасил була. Ачык сулыкларга агызылган 2,93 млн кубометрының нибары 440 мең кубометры гына тулысынча чистартыла. Карпов исемендәге химия заводының проект куәте тәүлегенә 4850 кубометр (бүгенгә фактик күләме 713 кубометр) су чистартырга исәпләнгән корылмаларына капиталь ремонт кирәк. Нәтиҗәдә тиешенчә чистартылмаган калдык сулар Пойма елгасын пычрата. "Менделеевсказот" җәмгыятенең чистарту корылмаларыннан тәүлек саен 3 мең кубометр калдык сулар үтә (проект куәте – 10 мең кубометр). Тик биредә дә аякларын юрганга карап сузарга мәҗбүрләр: су тиешле дәрәҗәдә биологик чистарыну үтми. Ярый әле ул табигатькә зыян салмый – кабаттан файдаланыла. Район биләмәләренә урнашкан данлыклы "Ижминводы" санаториендә дә калдык суларны чистарту белән бәйле хәлләр шулай ук әллә ни мактанырлык түгел. Мондагы су чистарту корылмаларына агымдагы ремонт ясыйсы бар, фильтрлар да күптәннән чистартылмаган. Билгеле инде, минераллардан арындырып бетерелмәгән суның Чулман елгасына агып ятуы экологларны сөендерми. Мондый кимчелекләр "Татгазэнерго"ның биологик чистарту корылмаларына да хас.

Ә бит киңәшмә эшендә катнашкан 4 районда ачык сулыкларга ел саен 11 млн 200 мең кубометрдан күбрәк калдык сулар төшә. Алда ясаган күзәтүләләрдән күренгәнчә, аның шактый өлеше тулысынча чистарыну үтми әлегә. Шуны ук каты көнкүреш калдыклары буенча да әйтергә мөмкин. Барлык мәйданнары 650 мең гектар тәшкил итүче Әгерҗе, Алабуга, Мамадыш һәм Менделеев районнары чүплекләре ел саен 510 мең тоннага артып тора. Шуның 54 меңе – көнкүреш, 44 мең ярымнан күбрәге – сәнәгать, 412 мең тоннасы – терлекчелек калдыклары. Мамадышта калдыклар кабул итү полигоны картасы тулган. Инде полигонның икенче чиратын сафка бастыру көн кадагында. Алабугадагысының да беренче чираты гына файдаланыла. Министрлыкның Кама яны территориаль идарәсе мәгълүматларыннан күренгәнчә, 2009 елның беренче яртысында барлыгы 22 мең 76 тонна икенчел чимал җыелган. Әлегә районнарда ул эш белән 13 оешма шөгыльләнә. Шуларның 10 ы кара һәм төсле металл әзерләү, аның эшкәртү һәм сату белән мәшгуль. Күргәнебезчә, бу җәһәттән эшлисе дә эшлисе әле.

Үз биләмәләреннән елына 300 мең тонна кара алтын чыгарылучы Менделеев районы урманнары белән дә мактана алмый. Монда алар өлешенә бөтен территориянең нибары 6,8% ы гына туры килә. Киңәшмәдә чыгыш ясаган республика урман хуҗалыгы министрының беренче урынбасары Зиннур Хәйруллин сүзләренә ышансаң, урманнар Татарстан мәйданының 18,7% ын алып тора икән. Район хакиме Рөстәм Гафаров исә үзләрендә ул күрсәткечне 10% ка җиткерү бурычы куелуын искәртә. Эшне мондый темплар белән алып барганда, уртача республика күрсәткеченә якынаер өчен бик күп тир түгәргә туры киләчәк әле аларга.

Рәис ЗАРИПОВ